| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«14» август 2026 ел** **№ 99**

Теләче муниципаль районында күренекле татар кулинары, кулинария буенча күп санлы китаплар авторы, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре Юныс Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган республика гастрофестивален уздыру турында

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлегенең 2026 елның 28 июлендәге 52 номерлы хатын карап, милли гастрономия традицияләрен торгызу, саклап калу һәм популярлаштыру максатларында, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 12 сентябрендә Теләче муниципаль районында күренекле татар кулинары, кулинария буенча күп санлы китаплар авторы, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре Юныс Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган республика гастрофестивале уздырырга.

2. Күренекле татар кулинары, кулинария буенча күп санлы китаплар авторы, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре Юныс Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган республика гастрофестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетын киләсе составта төзергә:

| | | |
|---|---|---|
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, оештыру комитеты рәисе; |
| Хәмидуллина Л.Ф. | - | Теләче муниципаль районы МБУ «Район мәдәният йорты» директоры вазыйфаларын башкаручы, оештыру комитеты сәркатибе; |
| Заһидуллин Р.Ш. | - | Теләче муниципаль районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча); |
| Иксанов Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Дәүлиева Р.М. | - | Теләче муниципаль районы МБУ Җирлекара китапханәсе директоры (килешеп); |
| Яхин Р.Р. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы рәисе; |

| | | |
|---|---|---|
| Хужин Л.Й. | - | «Татмедиа» АҖ филиалы «Теләче-информ» мәгълүмат үзәге директоры (килешү буенча); |
| Имамиева Ф.М. | - | Теләче муниципаль районы «Теләче туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе директоры. |

3. 2026 елның 17 августына кадәр күренекле татар кулинары, кулинария буенча күпсанлы китаплар авторы, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре Юныс Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган республика гастрофестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетына:

- гастрофестивальнең үткәрелү вакытын, этапларын билгеләргә;
- гастрофестиваль үткәрү турында Нигезләмә эшләп чыгарырга һәм расларга;
- жюри составын расларга.

4. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеген (Иксанов Д.С.) күренекле татар кулинары, кулинария буенча күп санлы китаплар авторы, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре Юныс Әхмәтҗанов истәлегенә багышланган республика гастрофестивален оештыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин